ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕМЕЛЬКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

14. 11. 2020 ел № 8

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы
нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 5 ноябрендәге
100 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 05.11.2019 ел, №100 Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге карары белән расланган, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**
«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә;»

2. Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru.

Совет рәисе,
Емелькино авыл җирлеге башлыгы: Н.И. Михайлова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЕМЕЛЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ